# Ислам нуры

«Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәту бар»
(Коръән Кәрим. 2-256)

12+

№9 (709) | 14 май 2020 ел | (1441, Рамазан) | Дини-иҗтимагый газета | 1995 елдан чыга


*2020 ел - ТАССР төзелүгә 100 ел, Татарстанда Туган тел елы*

## КУЛЫҢНАН КИЛСӘ, ИТ КЕЧЕЛЕК...



Бөтен дөнья коронавирус инфекциясе таралу нисбәтеннән борчыла. Әмма бу һич кенә дә хәйриячелек турында оныту өчен сәбәп түгел.

Апрель башыннан "Ярдәм" милли ислам хәйрия фонды "Тормыш юлы" дип аталган акция башлады. Әлеге акция кысаларында, нинди милләттән һәм нинди дин тотуына карамастан, физик мөмкинлекләре чикле кешеләр - күрмәүчеләр, ишетмәүчеләр, арбада утырып йөрүчеләр, ДЦП диагнозлы кешеләр, ялгыз карт-карчыклар, азкеремле, күп балалы гаиләләр, инвалид балалары булган әниләр, Бөек Ватан сугышы ветераннары, чит илдән килеп, авыр хәлдә калган студентлар көн саен бушлай кайнар ашлар белән тәэмин ителә. "Ярдәм" фонды волонтерлары, яңа гына пешкән ризыкны ланч-боксларга салып, бөтен Казан буенча өләшеп йөри. Кирәк булган очракта дарулар да, саклык маскалары да илтеп бирә.

"Тормыш юлы" проектын гамәлгә ашырганда иминлек мәсьәләләренә зур игътибар бирелә. Кайнар ризыкны өләшергә чыгып киткәнче, волонтерлар медицина күзәтүе үтә, аларга сәламәтлекләре турында белешмә бирелә. Алар белән куркынычсызлык кагыйдәләренә кагылышлы инструктаж уздырыла. Шулай ук волонтерларга ТР Яшьләр эшләре министрлыгыннан яки "Ярдәм" фондыннан аларның волонтер булуы хакында белешмә тапшырыла. Кайнар ашларны мохтаҗларга өләшкәндә, волонтерлар кулларына – перчатка, битләренә маска кияләр. Ризыкны хуҗаларына тапшырганда, саклык чараларын истә тоталар. Турыдан-туры кулга бирмиләр, алдан әзерләнгән урындыкка куялар. Волонтерлар ике адым артка киткәч кенә, хуҗалары ризыкны өенә алып кереп китә.

Мохтаҗларны тәмле ашлар белән сыйлауда һәркем катнаша ала. "Ярдәм" фонды булыша торган кешеләрнең исемлеге шактый зур, андагы кешеләр саны көннән-көн арта бара. Рамазанга кадәр 800гә якын кешене ашатсак, Рамазан аенда аларның саны күпкә артты - 2000нән артып китте. Рамазан ае керү белән, "Тормыш юлы" акциясе кысаларында "Хәйрия ифтарын өегезгә илтеп бирәбез" дигән проект эшли башлады. Ланч-бокслар төштән соң таратыла, ураза тотучылар аларны кичен ифтар алдыннан җылытып ашый.



Рамазан аеның 15 нче көнендә, Татарстан мөселманнары башлыгы Камил хәзрәт Сәмигуллин «Ярдәм» мәчетендә булып китте. Камил хәзрәтне Казан шәһәренең Киров һәм Мәскәү районнары имам-мөхтәсибе, ТР мөфтиенең социаль мәсьәләләр буенча киңәшчесе һәм мәчет имам-хатыйбы Илдар хәзрәт Баязитов, шулай ук акцияне уздыручылар һәм волонтерлар сәламләде.


Хәзерге вакытта "Ярдәм" милли ислам хәйрия фонды "Тормыш юлы" акциясен тормышка ашыру барышында социаль яктан начар якланганнар өчен барлыгы 8 проект белән эшли. Бу игелекле эшкә сез дә кушыла аласыз, дуслар! Без сезне игътибарга мохтаҗ кешеләргә ярдәм итәргә чакырабыз. Зур булмаган сумма да азкеремле кешеләр өчен - кайнар ризык кына түгел, ә рухи яктан зур ярдәм дә булчак.

Саклык банкы картасы номеры: 4274 2780 2038 4288 (Илдар Рәфкать улы Б. исеменә теркәлгән). +79600480778 телефон номерына тоташтырылган. (Назначение платежа: «Благотворительная помощь на кормление малоимущих»).

Әгәр кеше авыр хәлдә калган һәм ашарга пешереп ашарга мөмкинлеге юк икән, ул, 8 (843) – 258-07-78 телефоны аша шылтыратып, кайнар ризык китерүләрен сорый ала.

Өстәмә мәгълүмат өчен телефон - 89178646480.

## КАДЕР КИЧӘСЕ



Хакыйкать шулдыр ки, Без аны (Коръәнне) Кадер кичәсендә индердек.
Кадер кичәсенең нәрсә икәнен син беләсеңме?
Кадер кичәсе меңь айдан да хәерлерәк.
Ул көндә фәрештәләр вә Изге Рух (Җәбраил), Раббының рөхсәте илә, Аның әмерләрен җиренә җиткерер өчен, бер-бер артлы иңеп кенә торырлар.
Кадер кичәсе — иминлек кичәсе — таң ата башлаганга чаклы дәвам итәр.

**Коръәни-Кәрим, «Кадер» сүрәсе**

## Ифтарда булышыйм дисәң...



7 ел рәттән Рамазан аенда Казан шәһәрендә уздырылып килгән Республикакүләм ифтар бу елны 30 000 ураза тотучыга авыз ачтыруны үз өстенә алды. Әмма ТАССРның 100 еллыгына багышланган VIII Республикакүләм ифтар, Татарстанда гомуми үзизоляция режимы кертелү сәбәпле, бу елны дистанцион форматта үткәрелә – ифтар ризыклары ланч-боксларга җыелып өйгә китереп бирелә һәм халыкның бары тик мохтаҗ катлауларын гына күздә тота. Әлеге җыелмалар волонтёрлар ярдәмендә "Ак Барс Арена" стадионы һәм "Туган авылым" милли-туристик комплексы территориясендә тутырыла. 350 данәдән торган шундый ланч-боксларның бер өлеше 30 апрель көнне Чаллы шәһәре мөхтәсибәтенә дә кайтты һәм "Ихсан" фонды ярдәмендә ураза тотучы халыкка таратылды.

Әлеге социаль әһәмиятле проектны гамәлгә ашыруга үз өлешен кертергә теләүчеләр акчалата ярдәмне: 7715 кыска номерына «ИФТАР буш ара СУММА» тәртибендәге текст белән җибәрә ала. Мисал өчен, ИФТАР 300. СБ 5469 6200 1751 2813 ( Булат Раифович М. Полное наименование организации Благотворительный Фонд «Закят».) Белешмә өчен телефон - 89872253322.

# Кадер киче - Аллаһның бер бүләге

***Аллаһ Тәгалә Үзенең хикмәте илә кайбер ай вә көннәрне башкалардан өстен, мәртәбәле кылды. Елның Корбан, Гарәфә, Гашура көннәре, Кадер төне, атнаның җомга көне. Унике айның солтаны — Рамазан ае. Аллаһ Тәгалә ул вакытларны безләргә кимчелек-хаталарыбыздан пакьлану, әҗер-саваплар җыеп калырга олуг форсат итте. Корбан көнендә бугазланган малларыбыз гөнаһларыбыга кәффарәт, Гарәфә уразасы үткән һәм киләчәк, Гашура уразасы киләчәк елның гөнаһларын юа. Кадер төнен зикер вә гыйбадәттә уяу үткәрү мең айдан хәерлерәк.***

Рамазан ае — Коръән ае. Аллаһ Тәгалә әйтә: «Рамазан аенда кешеләргә туры юл, һидаять булып Коръән иңде». (Бәкара, 185). Бу изге айда кешелек дөньясына Аллаһның ахыр мөрәҗәгате - Коръән иңә башлады. Аллаһның рәхмәтен өмет итүче һәр иман иясе бу айда Коръән сүрәләрен укуын арттыра. Рамазан — Коръән ае, без — Коръән өммәте. Иң хөрмәтле, иң хәерле өммәткә иңде. Аллаһ Тәгалә бу Китапны без - Мөхәммәт өммәте укысын, мәгьнәләре хакында уйлансын, хөкемнәре белән гамәл кылсын өчен иңдерде. Кыямәт көнендә дә Коръән үз әһелләренә яклаучы булып, шәфәгать кылыр. Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтә: «Кыямәт көнендә ураза һәм Коръән адәм баласын яклаучы булырлар. Ураза: «Әй, Раббым! Бу бәндәңне көндезләрен ризыктан вә шәһвәттән тыйдым», — дияр. Коръән: «Әй, Раббым! Бу бәндәңне төннәрен йокыдан тыйдым. Мине аңа шәфәгатьче итсәң иде», — дияр. Шулвакытта ураза вә Коръән ул бәндәгә шәфәгать кылырлар».

Ибн Габбәс тапшыра, Рамазан аенда Җәбраил фәрештә һәр төн килеп пәйгамбәребезгә (с.г.в.) Коръән өйрәткән. Пәйгамбәребез үзенең бөтен сәхабәләрен дә Рамазанда Коръән укырга чакырды. Мисал белән Габдулла ибн Гамрга: «Һәр өч көндә укып чык», — диде. Сәхабәләрнең кайберләре Коръәнне өч көндә, икенчеләре җиде көндә, өченчеләре ун төндә укып хәтем кылдылар. Бөтен ислам галәменә мәшһүр булган Имам Әбү Хәнифә һәм Имам Шәфигый хәзрәтләре Рамазан буена алтмыш тапкыр Коръәнне укып чыкканнар, дип риваять кылына. Аларның никадәр Коръәнгә якын булуларын күреп, безнең никадәр Аллаһ китабыннан ерак торуыбызны аңлыйсың.

Газиз кардәшләрем, шуны да әйтергә кирәк, күләм артыннан куып, Коръән укуның төп максатын онытырга ярамый, Аллаһ Тәгалә Коръәндә: «Әллә алар Коръән хакында уйланмыйлармы?» — диде. Коръән аятьләрен уку гына түгел, аларның мәгьнәләрен дә карап, уйланырга, Коръән белән гамәл кылырга кирәк. Ашыгып хәрефләрнең әйтелешләрен, тәҗвид кагыйдәләрен игътибарсыз калдыру ярамас. Коръән өлкәсендә олуг гыйлеме белән аерылып торган сәхабә Ибн Габбәс әйтә: «Минем өчен Коръәннән ачык итеп бер сүрәне укуым ашыгып тулы Коръәнне укудан хәерлерәк».

Рамазан аен ел буе сагынып көтсәң дә, изге көннәр сизелми дә үтә. Көн арты көн килеп, Раббысына тугры бәндә кадерле вакытларны изге гамәл, Коръән укуга сарыф итә. Тоткан ураза калебне йомшарта, торган кыямнар сабыр, әхлаклы итә, укыган аятьләр гафиллектән уята. Тән итәгать кыла, тел зикер итә, җан уйлана, гыйбрәт ала. Кунакның китәр вакытлары җиткәч, кадере арта. Рамазанның ахыргы ун көне. Ул көннәрдә иман әһеленең изгелекләре өстәлә, «Рәхмәтенә ирешермен, гөнаһымнан пакьләнермен, уттан котылырмын», — дигән өметләр арта. Гаишә р.г. әйтә: «Аллаһның илчесе Рамазанның ахыргы ун көнендә башка көннәренә карыйныграк иҗтиһад тырышлык күрсәтте». (Мөслим)

Хәсән әл-Басри әйтә: «Бер көннең таңы килсә, бәндәгә эндәшер: Әй Адәм баласы, мин яңа мәхлук, синең гамәлеңә шаһитмын. Изге гамәл белән миннән хәстәрлек күр, мин кабат кайтмыймын».

«Рамазанның ахыргы ун төне җитсә, Аллаһның илчесе (с.г.в.) төннәрен намазларда үткәрде, гаиләсен уятты. Гыйбадәттә аеруча зур тырышлык күрсәтте һәм изәрен катырак бәйләде.» (Изәр — чалбар. Пәйгамбәребез с.г.в. ул вакытларын хатыннарыннан башка үткәргән.)

«Аллаһның илчесе рамазанның ахыргы ун төнен мәчеттә үткәрде һәм: «Кадер төнен рамазанның ахыргы ун төнендә эзләгез», - диде. (Бохари һәм Мөслим.) Әйе, Рамазанның ахыр ун төне безгә башына таҗ кигән Кадер төнен алып килә. Ул төннәрнең берсен кулдан ычкындырсаң, кире кайтара алмыйсың.

«Дөреслектә Без аны (Коръәнне) Кадер төнендә иңдердек. Кадер төненең хикмәтен сиңа нәрсә белдерде. Кадер төне мең айдан хәерлерәк. Ул төнне Аллаһның теләге илә барча әмерләр белән фәрештәләр һәм Рух (Җәбраил) иңә. Ул таң беленгәнче иминлектер». (Кадер сүрәсе).

Ибн Габбәс әйтә: «Кадер төнендә Аллаһ Коръәнне Ләүхүл-Мәхфүздән дөнья күгендәге Бәйтүль Гыйззәгә берьюлы иңдерде. Соңыннан Коръән 23 ел дәверендә пәйгамбәребезгә (с.г.в.) кисәк-кисәк булып иңде».

Ни өчен ул төн Кадер төне дип аталды? Кадер — кодрәт, бу төн Аллаһ каршында иң кодрәтле һәм иң хөрмәтле төндер. Кадер – тәкъдир, бу төндә ел әйләнәсенең язмышы тәкъдир кылына. Аллаһ Тәгалә әйтте: «Ул төндә һәрбер хикмәтле эш бүленә». (Дүхан — 4).

Соңра Кадер төнен Коръән иңү белән үзенчәлекле иткән Аллаһ ул төннең тагын бер өстенлеген бәян итеп: «Кадер төне мең айдан хәерлерәк», — дия. Ул төнне гыйбадәттә, намаз, Коръән уку, зикерләр әйтү һәм дога кылуда үткәрү мең ай гыйбадәтеннән дә хәерлерәк. Мең ай ул 83 ел һәм 4 ай була.

Ул төндә җир йөзенә Аллаһ кешеләргә тәкъдир кылган һәрбер яхшы вә яман эш белән Җәбраил һәм башка фәрештәләр төшәләр. «Ул таң беленгәнче иминлектер». Ягъни Кадер төнендә җир өстенә төшкән фәрештәләр бәрәкәт, тынычлык һәм хәерлелек белән төшәләр. Бигрәк тә ул фәрештәләр Коръән укучылар, Аллаһны зикер итүчеләр һәм гыйлем эстәүчеләр белән бергә булалар. Шайтан да ул төнне үзенең мәкерлекләрен кыла алмый.

Пәйгамбәребез (с.г.в.) Кадер төненең намазлары турында: «Кем Кадер төнен иман белән һәм Аллаһның әҗерен өмет итеп кыямда үткәрә, аның элек кылган гөнаһлары гафу ителә», — диде. (Бохари, Мөслим).

Гаишә р.г. пәйгамбәребездән (с.г.в.): «Кадер төненә ирешсәм нәрсә дип әйтим?» — дип сорагач, Ул (с.г.в.): «Әллаһүммә иннәкә Гафүввүн, түхиббү-льгафвә фәгьфү ганнии» дип әйт», — диде. (Тирмизи)

Кадер төне кайчан була? Бу мәсьәләдә галимнәр төрле фикердә. Берәүләре Кадер төне егерме беренче көнендә, икенчеләре егерме өчендә, өченчеләре егерме бишендә, дүртенчеләре егерме тугызында диләр. Күбесе егерме жидесендә дигән фикердә. Пәйгамбәребез (с.г.в.) мөбарәк төнне соңгы ун төннән эзләде. «Кадер төне — Рамазанның ахыргы ун төнендә. Кем аларны уяу үткәрә, Аллаһ аның кылган һәм кылачак гөнаһларын кичерә. Бу да так санлы төндә. Тугызынчы, жиденче, бишенче яки өченчесендә».

Кадер төненең үз галәмәтләре бар. Пәйгамбәребез с.г.в. әйтте: «Кадер төненең галәмәтләреннән: ул якты ай кебек саф, нурлы, тыныч, имин, салкын да, эссе дә түгел. Һәм ул төнне бер йолдызга да атарга хәләл түгел». «Ул көннең кояшы нурсыз, тулы ай кебек. Шайтанга ул көнне кояш белән чыгарга хәләл булмый».

Рамазан аенда Аллаһ Тәгалә Үз бәндәләренә изгелек кылырга Үзе ярдәм итә. Чөнки бәндә белә, җәннәт ишекләре ачык, ут ишекләре ябык. Шайтаннар чылбырлар белән богауланган. Аларның көчләре башка айлардагы кебек түгел. Пәйгамбәребез әйтә: «Рамазан аеның беренче киче булса, шайтаннарга богаулар салыныр, җәһәннәм ишекләре ябылыр, берсе дә ачылмас. Җәннәт ишекләре ачылыр, берсе дә ябылмас. Аллаһтан бер эндәшүче әйтер: «Әй изгелеккә ашыгучы бәндә! Ашык изгелеккә. Әй, явызлыкны теләүче бәндә! Туктат явызлыгыңны. Бу айда Аллаһ Тәгалә бәндәләрен җәһәннәм утыннан коткарыр. Уттан котылу Рамазанның һәр кичендәдер». Рамазан аенда кылган изгелекләр өчен бәндә башка бер айда да алмаган саваплар ала. Чөнки пәйгамбәребез (с.г.в.): «Кем Рамазан аенда Аллаһка бер сөннәт белән якыная, аңа фарыз кылган әҗер була. Кем бер фарыз кыла, җитмеш фарыз әҗерен ала», — диде. (Ибн Хүзәймә, Бәйһәкый...)

Рамазан - юмартлык ае. Ибн Габбәс тапшыра: «Аллаһның илчесе кешеләрнең иң юмарты булды. Рамазан аенда Җәбраил фәрештә килеп Коръәнне өйрәткәндә аның юмартлыгы тагын да артты». (Бохари, Мөслим). Имам Әхмәт риваятендә: «... Ни хакында соралмасын, бирде», - дигән өстәмә бар. Гаишә: «Аллаһның илчесе, Рамазан җитсә, һәр әсирне азат итә, һәр сораучыга бирә иде», — диде. (Бәйһакый).

Юмартлык — Аллаһ Тәгаләнең сыйфаты. Пәйгамбәребез (с.г.в.): «Аллаһ юмарт, юмартлыкны сөя», - диде. (Тирмизи). Аллаһ юмартларның-юмарты, Аның юмартлыгы кайбер вакытларда тагын да артты. Рамазан аенда да Аллаһ Тәгалә башка вакытлардан юмартрак иде. Пәйгамбәребез дә һәрвакыт ничек кенә юмарт булмасын, Рамазан аенда аның юмартлыгы өстәлде. «Иң хәерле сәдака — Рамазан садакасы», — диде. (Тирмизи).

Рамазан ае — ифтарлар, авыз ачулар ае. Ураза тотучыга авыз ачтыру да савап тупларга олуг форсат. Пәйгамбәребез (с.г.в.): «Рамазан аенда ризык арта. Кем бер уразалыга авыз ачтыра, аның бу эше гөнаһлары кичерелүгә, тәне уттан котылуга сәбәп була. Ураза тотучыга уразасы өчен күпме әҗер булса, аңа да шулкадәр савап була. Моның белән ураза тотучының әҗере һич кимемәс», — дип өммәтен юмартлыкка чакырды. Рәсүлебезнең бу сүзләрен ишеткән сәхабәләр бик тәэсирләнделәр. Ләкин ифтар кылдыру өчен мөмкинлек барысында да юк иде. Алар: «Әй Аллаһның илчесе, барыбыз да уразалыга авыз ачтырырга мөмкинлек таба алмыйбыз бит?» — дип аптыраштылар. Әлхәмдүлилләһ, Аллаһ бәндәләренә рәхимле, изге гамәл кылырга ният итүчегә җиңеллек бирүче. Пәйгамбәребез (с.г.в.) аларны: «Аллаһ бу савапны хөрмә яки су йотымы белән ифтар кылдыручыга бирә. Кем бер уразалыны эчертә, Аллаһ аны Кыямәт көнендә судан эчертә. Ул судан соң бәндә җәннәткә кергәнче сусамас», — дип сөендерде.

Аллаһның рәхмәте - ураза тотып чиксез әҗер аласың, өстәвенә, башка уразалыны ифтар кылдырып, ике кешенең ураза әҗерен кәсеп итәсең.

Әй газизләрем, юмартлыкларыгызны туплагыз, сәдака ае килде. Әй мал ияләре, байлыкларыгызны кызганмагыз, саран байның җаны факыйрь. Җәннәт капкалары ачылган айда бирегез. Кем Аллаһның бәндәләренә юмарт - Аллаһ ул бәндәсенә юмарт. Мәдинә шәһәрендә бер мөселман вафат булгач, аның яшерен сәдакалары ачыла. Мөселманнар аның тәнен юганда аркасында төннәрен Мәдинә фәкыйрьләренә капчык белән он ташыганнан суелып каралган эзләр күрәләр. Шайтан: “Сәдака бирсәң фәкыйрьләнерсең”, — дип куркыта. Пәйгамбәребез (с.г.в.): «Сәдака малны киметмәс», — ди. Аллаһ бирүчегә бирә, саранныкын ала. «Һәркөн иртә белән ике фәрештә җиргә төшә һәм берсе: Йә Аллаһ, бирүчегә бирсәң иде”, - дип, икенчесе: “Йә Аллаһ, саранлык белән үзендә калдыручыныкын тартып алсаң иде”, — дип дога кылалар». (Бохари, Мөслим).

Пәйгамбәребезнең шәкертләре — сәхабәләр бездән иманлы, бездән тәкъва, бездән гыйлемле, бездән зирәк булдылар. Алар Аллаһның нигьмәте булган фазыйләтле вакытларны кадерләделәр. Рамазанга алты ай кала: «Йә Аллаһ, безне исән-сау Рамазанга, Рамазанны безгә ирештерсәң иде!» — дигән догада булдылар. «Йә Аллаһ, безне Рамазанның уразасы һәм кыямы белән ризыкландырсаң иде. Безгә Рамазанда юмартлык, тырышлык, куәт һәм һиммәт насыйб итсәң иде. Фетнәләрдән сакласаң иде», — дип Аллаһтан ярдәм сорадылар.

Газиз кардәшем, Рамазан аена ирешкәч, Аллаһка шөкер ит. Бу Рамазан минем өчен бәлки соңгы Рамазандыр дип фикер йөрт. Кем белә, тагын Рамазанга ирешерсеңме? Бер елдан да ураза тотырлык саулыгың булырмы? Аякларыңда тәравихларда торырлык көч калырмы? Бер иман иясе үлем түшәгендә ятканда елап җибәргән, үзенең елавын шулай аңлаткан: «Ураза тотучылар ураза тота, мин алар белән түгел. Намаз укучылар намазда, ә мин монда, алар белән түгел».

Бу Рамазан аендагы гыйбадәтең узган елныкыннан артык булсын.

**Йосыф хәзрәт ДӘҮЛӘТШИН, Казанның Идел буе һәм Вахитов районнары имам-мөхтәсибе**

«Ислам нуры»на - 25 ел!

# Аллаһның рәхмәтенә ирешсәк иде

Һәрбер гамәлнең нәтиҗәсе була, нәтиҗәсез гамәл мәгънәсез була. Менә уразаны да Аллаһы Тәгаләбезнең ризалыгын өмет итеп тотабыз. Беренче ун көн гөнаһлардан котылу ун көнлеге, икенче ун көнлек Аллаһның рәхмәтенә ирешү көннәре, өченче ун көн җәһәннәм утыннан котылу көннәре диеп, шатланып. Аллаһның ахирәтенә иман китергән кеше өчен Аллаһның рәхмәтенә ирешеп, җәһәннәм утыннан котылудан да зуррак бәхет бармы икән?! Әлбәттә, юктыр. Быелгы Рамазаныбызда авыр шартларга туры килде, башка елларда намаз укучы кардәшләребездән нурланып торган мәчетләребезне бикләдек, кардәшлегебезне арттырып ифтарлар кыла алмадык. Барысы да Аллаһы Тәгаләбезнең кулында, без күнүчеләр генә. Ахырлары хәерле булып, алдагы елларда хәерле Рамазан айлары булсын инде. Инде менә мөселманнарның ике зур бәйрәменең берсе булган ураза бәйрәмендә безгә гамәлләребезгә нәтиҗә чыгарып вакыт житеп килә. Кардәшләрем, нәтиҗә чыгарыйк: кайда хатабыз, нигә Раббыбыз безгә бу сынауларны бирде?.. Пәйгәмбәребез (с.г.в.) әйтә: "Әгәр кешеләр арасында каршылык туса, сез күпчелек белән булыгыз", - ди. Өммәтебезнең бүгенге зур афәте - безнең таркаулыгыбыз. Сөннәт һәм җәмәгать әһелләребез диеп әйтергә яратабыз, ләкин гамәлдә киресенчә килеп чыга. Инде шул гает намазына гына ярыйсы җыела идек, бу ел гает намазына да җыела алмабыз. Ана карамастан, Рамазан гаете безнең зур бәйрәмебез, шушы бәйрәмебез безгә бергәлек алып килсен, мөфтиятебез кысаларында безгә берләшү насыйп булсын, кардәшләрем, берләшүнең бүген башка юлы юк. Аңласак икән: шайтан коткысы, нәфес коткысына бирешеп, фетнәләнеп йөрүдән беркемгә дә, бер файда да юк. Динебезгә хезмәт итүчеләр булыйк, Аллаһ һәммәбезгә исәнлек, бәхет насыйп итсен. Ураза бәйрәмен иминлектә каршыларга язсын!

**Рәис хәзрәт ӘХМӘТОВ, Чаллының "Сөембикә" мәчете имам-хатыйбы**

---

**СОРАУ-ҖАВАП**

**Укучылардан килгән сорауларга шәригать белгече Рәфыйк хәзрәт МИННӘХМӘТОВ җавап бирә**

**Сорау. 1. Китапларда намазны вакыты керү белән укырга, диелгән. Ә кайберләрендә әйтелгән: "Бераз соңарып уку саваплырак", - дигәннәр. Кайсы дөрес икән? 2. Мәчет намазын кайберәүләр зәвәл белән өйлә арасында уку дөрес түгел ди, кайберәүләр: "Зәвәлгә тикле дә, зәвәлдән соң да ун минут калдырып укырга кирәк", - ди. Г.Саматовның шәригать китабында (1 том, 235 бит) зәвәл вакытында укысаң да дөрес, диелгән.**

**Салих ЗИННӘТОВ, Зәй районы Аксар авылы**

**Җавап.** 1. Фарыз намазларының вакыты иркен – бер намаз вакыты кереп икенче намаз вакыты кергәнче укысаң, вакытында укылган санала. Шулай да бу иркен вакытның яхшырак, мөстәхәб өлешендә уку тагы да саваплырак, пәйгамбәребезнең сөннәтендә әйтелгәнчә. Мәсәлән: 1) иртәнге намазны яктыргачрак уку; 2) өйләне кышын вакыты керү белән уку, ә җәен (бигрәк тә чилләдә) икендегә табарак соңартып уку; 3) икендене соңрак уку; 4) ахшамны вакыты керү белән уку; 5) ястүне соңартыбрак уку (төннең өчтән бер өлеше үткәндә). Хәнәфи мәзһәбеннән аермалы буларак, шәфигый мәзһәбендә һәр намазны да вакыты керү белән уку яхшырак санала.

2. Тәхиятел-мәчет намазы нәфел намазы санала. Нәфел намазларын түбәндәге вакытларда уку ярамый: 1) таң беленгәннән алып кояш чыгып офыктан сөнге биеклеге күтәрелгәнче; 2) зәвәл вакытында, ягъни календарьларда зәвәл вакыты дип билгеләнгән вакытның ике ягыннан да ким дигәндә бер биш минут; 4) икенде намазыңны укыганнан соң кояш баеп беткәнче.

---

# Кылган хаҗым - Аллаһ биргән таҗым

(*Дәвамы. Башы газетаның алдагы саннарында*)

Изге урыннарга экскурсия ясап кайтканнан соң, икенче яртыда госел коенып, ихрамны киеп, изге Мәккә шәһәренә кузгалырга команда көтәргә кушылды.

Өстебездә хаҗ киеме – ихрам. Ирексездән елыйсы килә. Күңелдәге дулкынлануны, хисләр давылын аңлатып та булмый. Аллаһка тапшырып, автобусларга утырып кузгалдык. Биш сәгать барачакбыз, диделәр. Юлда туктатып, «Хаҗи, хаҗи» дип, безгә ашарга-эчәргә кертәләр. Микат Мәккәгә бару юлында була, дип аңлатты Тимергали хәзрәт. Микат – күңелең белән хаҗ кылырга ниятләп ихрамга керү, ягъни, ике рәкагать намаз укып, хаҗ гамәлен кылырга ниятләү. Мәдинәдән баручыларга, шул исәптән Рәсәйдән килүчеләргә, микат Зөлхөләйфә дигән урында. Гомумән, дөньяның төрле почмагыннан килүчеләргә алты микат бар.

Тәлбия әйтеп, юлыбызны дәвам иттек. Һәркем үз уе, үз хисләре белән. Иреннәр шушы изге гамәлнең кабул булуын теләп кыймылдый. Ләббәйкә-лааһүммә ләббәйкә, ләббәйкә ләә шәрикә ләкә ләббәйкә, иннәл-хәмдә үән-нигмәтә ләкә үәл-мүлкә, ләә шәрикә ләк. Мәгънәсе: Я Рабби, мин Синең каршыңда, мин Синең каршыңда, Синең һичбер тиңдәшең юк. Дөреслектә, барча мактау һәм нигъмәт Сиңа хас һәм хуҗалык та Сиңа хас. Синең бернинди тиңдәшең юк.

Төн караңгысында әл-Хәрам мәчетенең сәгать утлары балкып күренде. Әкрен генә әйтә башлаган тәлбия көчәйгәннән көчәя. Ирексездән күзләрдән яшь ага. Кемдер кыйбла эзләп бәргәләнгәндә, мин – гади бер колхозчы малае, Кәгъбәтулла каршында басып торам. Телевизор экраннарыннан, рәсемнәрдән генә күргән Кәгъбәтулла. Моңа кадәр нәселемдә берәүгә дә тимәгән бәхет миңа тиде.

Халык дулкыны су ташкыны кебек агып тора. Тиешле догаларны укый-укый, бер-беребездән калмаска дип, Аллаһ ризалыгы өчен без дә Тәвафыбызны башлап җибәрдек. Тәваф өстә яшел ут янган урыннан, Кара таш куелган почмактан башланып, сәгать теленә каршы кылына. Беркем беркемне күрми, иреннәр дога кабатлый, күзләрдән мөлдерәп яшь ага. Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) «Атлаган һәр адымың саен бер гөнаһың кимеп, бер савап языла» дигән хәдисе бар. Бу җир йөзендә гөнаһсыз кем бар икән?! Һәркем Аллаһыдан ярлыкау сорый, өмет итә.

**Рәфкать ШАҺИЕВ, Әлмәт** (*Дәвамы бар*)

---

**ӘДӘБИ СҮЗ**

## *Ураза ае*

*Х* Хак Тәгалә бүләк иткән*
*У* Уникe айның энҗесе -*
*Ш* Шатлык, мәгърифәт ае.*
*К* Коръәне белән нурлап*
*И* Инсанына көч бирүче*
*Л* Лаек гыйбадәт ае.*
*Ә* Әдәп-әхлакны бизәгән*
*Й* Йомшаклык, шәфкать ае.*
*Д* Дәрәҗә-сөю арттырган*
*Ә* Әҗер-саваплар ае.*
*Р* Рәхмәтле вә миһербанлы,*
*А* Ашыкмый, сабыр булып,*
*М* Матур ифтарлар корып,*
*А* Аңлап Китабын укып,*
*З* Зиннәтләнсәк бу айда,*
*А* Аллаһыбыз ризалыгын*
*Н* Насыйп әйләр, иншәалла!*

***Фәнисә ФӘХРЕТДИНОВА,***
***Башкортстанның Чакмагыш районы***
***Әхмәт авылы***

---

Әни сүзе

# Балаларыбыз иманлы булсын!


«Карагыз, нинди искиткеч табигать!» - диде минем олы улым Сөләйманым, беркөнне урамга чыккач. Гаддәтә, бу - минем сүзләрем иде. Урамга чыккан саен табигатькә хозурланып, кулларымны шатлыктан өскә күтәреп: «Карагыз, балаларым, нинди искиткеч табигать!» - дим мин үзем. Һәр көнебез төрле, айлар да шулай ук төрле, Аллаһыбыз ел фасылларын да ничек үзгәрешле итеп яраткан... Аллаһыбызның бар иткән әйберләрен санап бетергесез, балалар белән көн дә бер әйберне карап, өйрәнеп узсаң да, вакыт һәм дәресләр җитеп бетми! Минем уйлавымча, әни кеше тирә-якта булган предметның, үсемлекнең, бөҗәкнең бу табигатьтәге ролен балага тиешенчә күрсәтергә, аңлатырга тиеш. Әтиебез беркөнне суалчаннарның туфракта нинди вазыйфа башкарганын балаларыбызга сөйләп узды. Күрәсең, исләрендә калдырганнар, сеңдергәннәр: чөнки беркөнне яңгырдан соң урамда яткан суалчаннарны күреп, балаларым әтиебезнең узган дәрестә сөйләгән сүзләрен сөйләп бирделәр! Балага мөрәҗәгать итә торган сүзләр һәм әңгәмәләр эзсез калмый дигән фикергә тагын бер мәртәбә инанырга туры килде. Минем игътибар белән тыңлавым, сораулар бирүем балаларымның тагын да мавыктыргыч итеп сөйләүләренә бер этәргеч булды. Нарат күркәсен җирдән алып, бәләкәй улым: «Моны да Аллаһ бал иткән», - дип, миңа бирде. Минем: «Әйе, балам, дөрес әйтәсең, моны да Аллаһ бар иткән, мин бу нарат күркәсен кесәмә тыгып куям, әтиебезгә күрсәтербез», - дип әйткән җылы сүзләрем балаларымда тагын да нәрсәдер эзләп, аңа сокланып, Аллаһ бар иткәнен аңлап, әтиебезгә алып кайтырга дәрт уятты. Шулай итеп минем уларым эзләү эшенә керешәләр... Агач ботагымы, яфракмы, агулы гөмбәме, берәр бөҗәкме - барысына да: «Аллаһ бар иткән», - диешә-диешә, «археологик» эшләрен дәвам итәләр. Балаларымның Аллаһ Тәгаләне «Бар итүче» дип танулары, аңлаулары мине әни кеше буларак һәм ислам динебезне, дуслык, чисталык, гадел динебезне балаларыма тапшырырга теләгән кеше буларак бик сөендерә! Димәк, әти-әнинең сүзләре балаларга бик тәэсир итә икән... Балалар сорау яудырганда, әти-әни сабырлык күрсәтеп, көләч йөзе белән җавап бирсен иде, шул теләкләремне үземнең гаиләмә дә телим. Чөнки безнең бердәм, тату гаилә буласыбыз килә. Тәүфикълы, иманлы, җәмгыятебезгә файда китерә торган балалар тәрбияләп үстерәсебез килә, амин!

**Алинә ХӘБИБУЛЛИНА, Чаллы шәһәре**

# Июнь аена намаз вакытлары

| Милади апрель | Көн исеме | Шәүвәл, зөлкагъдә | Иртәнге намаз: Таң беленә, Уфа | Иртәнге намаз: Таң беленә, Чаллы | Иртәнге намаз: Таң беленә, Казан | Иртәнге намаз: Мәчетләрдә укыла, Уфа | Иртәнге намаз: Мәчетләрдә укыла, Чаллы | Иртәнге намаз: Мәчетләрдә укыла, Казан | Кояш чыга, Уфа | Кояш чыга, Чаллы | Кояш чыга, Казан | Зәвәл, Уфа | Зәвәл, Чаллы | Зәвәл, Казан | Өйлә, Уфа | Өйлә, Чаллы | Өйлә, Казан | Икенде, Уфа | Икенде, Чаллы | Икенде, Казан | Ахшам, Уфа | Ахшам, Чаллы | Ахшам, Казан | Ястү, Уфа | Ястү, Чаллы | Ястү, Казан |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Дш | 9 | 2:28 | 00:53 | 01:06 | 03:05 | 01:23 | 01:36 | 04:45 | 02:53 | 03:06 | 13:14 | 11:28 | 11:41 | 13:30 | 12:00 | 12:00 | 18:54 | 17:11 | 17:24 | 21:41 | 20:03 | 20:17 | 23:11 | 21:33 | 21:47 |
| 2 | Сш | 10 | 2:27 | 00:52 | 01:05 | 03:04 | 01:22 | 01:35 | 04:44 | 02:52 | 03:05 | 13:14 | 11:28 | 11:41 | 13:30 | 12:00 | 12:00 | 18:55 | 17:11 | 17:25 | 21:43 | 20:04 | 20:18 | 23:13 | 21:34 | 21:48 |
| 3 | Чш | 11 | 2:26 | 00:51 | 01:04 | 03:04 | 01:21 | 01:34 | 04:44 | 02:51 | 03:04 | 13:14 | 11:28 | 11:41 | 13:30 | 12:00 | 12:00 | 18:56 | 17:12 | 17:25 | 21:44 | 20:06 | 20:19 | 23:14 | 21:36 | 21:49 |
| 4 | Пж | 12 | 2:24 | 00:50 | 01:03 | 03:03 | 01:20 | 01:33 | 04:43 | 02:50 | 03:03 | 13:15 | 11:28 | 11:41 | 13:30 | 12:00 | 12:00 | 18:57 | 17:13 | 17:26 | 21:45 | 20:07 | 20:20 | 23:15 | 21:37 | 21:50 |
| 5 | Жм | 13 | 2:23 | 00:50 | 01:02 | 03:02 | 01:20 | 01:32 | 04:42 | 02:50 | 03:02 | 13:15 | 11:28 | 11:42 | 13:30 | 12:00 | 12:00 | 18:58 | 17:13 | 17:27 | 21:46 | 20:08 | 20:21 | 23:16 | 21:38 | 21:51 |
| 6 | Шм | 14 | 2:22 | 00:49 | 01:02 | 03:01 | 01:19 | 01:32 | 04:41 | 02:49 | 03:02 | 13:15 | 11:29 | 11:42 | 13:30 | 12:00 | 12:00 | 18:58 | 17:14 | 17:27 | 21:47 | 20:09 | 20:23 | 23:17 | 21:39 | 21:53 |
| 7 | Як | 15 | 2:22 | 00:48 | 01:01 | 03:00 | 01:18 | 01:31 | 04:40 | 02:48 | 03:01 | 13:15 | 11:29 | 11:42 | 13:30 | 12:00 | 12:00 | 18:59 | 17:15 | 17:28 | 21:48 | 20:10 | 20:24 | 23:18 | 21:40 | 21:54 |
| 8 | Дш | 16 | 2:21 | 00:47 | 01:00 | 03:00 | 01:17 | 01:30 | 04:40 | 02:47 | 03:00 | 13:15 | 11:29 | 11:42 | 13:30 | 12:00 | 12:00 | 18:59 | 17:15 | 17:29 | 21:49 | 20:11 | 20:25 | 23:19 | 21:41 | 21:55 |
| 9 | Сш | 17 | 2:20 | 00:47 | 01:00 | 02:59 | 01:17 | 01:30 | 04:39 | 02:47 | 03:00 | 13:15 | 11:29 | 11:42 | 13:30 | 12:00 | 12:00 | 19:00 | 17:16 | 17:29 | 21:50 | 20:12 | 20:25 | 23:20 | 21:42 | 21:55 |
| 10 | Чш | 18 | 2:19 | 00:46 | 00:59 | 02:59 | 01:16 | 01:29 | 04:39 | 02:46 | 02:59 | 13:16 | 11:29 | 11:43 | 13:30 | 12:00 | 12:00 | 19:00 | 17:16 | 17:30 | 21:51 | 20:13 | 20:26 | 23:21 | 21:43 | 21:56 |
| 11 | Пж | 19 | 2:19 | 00:46 | 00:59 | 02:58 | 01:16 | 01:29 | 04:38 | 02:46 | 02:59 | 13:16 | 11:30 | 11:43 | 13:30 | 12:00 | 12:00 | 19:01 | 17:17 | 17:30 | 21:52 | 20:14 | 20:27 | 23:22 | 21:44 | 21:57 |
| 12 | Жм | 20 | 2:18 | 00:46 | 00:58 | 02:58 | 01:16 | 01:28 | 04:38 | 02:46 | 02:58 | 13:16 | 11:30 | 11:43 | 13:30 | 12:00 | 12:00 | 19:01 | 17:17 | 17:31 | 21:53 | 20:15 | 20:28 | 23:23 | 21:45 | 21:58 |
| 13 | Шм | 21 | 2:18 | 00:45 | 00:58 | 02:57 | 01:15 | 01:28 | 04:37 | 02:45 | 02:58 | 13:16 | 11:30 | 11:43 | 13:30 | 12:00 | 12:00 | 19:02 | 17:18 | 17:31 | 21:53 | 20:15 | 20:29 | 23:23 | 21:45 | 21:59 |
| 14 | Як | 22 | 2:17 | 00:45 | 00:58 | 02:57 | 01:15 | 01:28 | 04:37 | 02:45 | 02:58 | 13:16 | 11:30 | 11:43 | 13:30 | 12:00 | 12:00 | 19:02 | 17:18 | 17:31 | 21:54 | 20:16 | 20:29 | 23:24 | 21:46 | 21:59 |
| 15 | Дш | 23 | 2:17 | 00:45 | 00:58 | 02:57 | 01:15 | 01:28 | 04:37 | 02:45 | 02:58 | 13:17 | 11:30 | 11:44 | 13:30 | 12:00 | 12:00 | 19:02 | 17:19 | 17:32 | 21:55 | 20:16 | 20:30 | 23:25 | 21:46 | 22:00 |
| 16 | Сш | 24 | 2:17 | 00:45 | 00:57 | 02:57 | 01:15 | 01:27 | 04:37 | 02:45 | 02:57 | 13:17 | 11:31 | 11:44 | 13:30 | 12:00 | 12:00 | 19:03 | 17:19 | 17:32 | 21:55 | 20:17 | 20:30 | 23:25 | 21:47 | 22:00 |
| 17 | Чш | 25 | 2:17 | 00:45 | 00:57 | 02:57 | 01:15 | 01:27 | 04:37 | 02:45 | 02:57 | 13:17 | 11:31 | 11:44 | 13:30 | 12:00 | 12:00 | 19:03 | 17:19 | 17:33 | 21:56 | 20:17 | 20:31 | 23:26 | 21:47 | 22:01 |
| 18 | Пж | 26 | 2:17 | 00:45 | 00:57 | 02:57 | 01:15 | 01:27 | 04:37 | 02:45 | 02:57 | 13:17 | 11:31 | 11:44 | 13:30 | 12:00 | 12:00 | 19:03 | 17:20 | 17:33 | 21:56 | 20:18 | 20:31 | 23:26 | 21:48 | 22:01 |
| 19 | Жм | 27 | 2:17 | 00:45 | 00:57 | 02:57 | 01:15 | 01:27 | 04:37 | 02:45 | 02:57 | 13:18 | 11:31 | 11:44 | 13:30 | 12:00 | 12:00 | 19:03 | 17:20 | 17:33 | 21:56 | 20:18 | 20:32 | 23:26 | 21:48 | 22:02 |
| 20 | Шм | 28 | 2:17 | 00:45 | 00:58 | 02:57 | 01:15 | 01:28 | 04:37 | 02:45 | 02:58 | 13:18 | 11:32 | 11:45 | 13:30 | 12:00 | 12:00 | 19:04 | 17:20 | 17:33 | 21:57 | 20:18 | 20:32 | 23:27 | 21:48 | 22:02 |
| 21 | Як | 29 | 2:17 | 00:45 | 00:58 | 02:57 | 01:15 | 01:28 | 04:37 | 02:45 | 02:58 | 13:18 | 11:32 | 11:45 | 13:30 | 12:00 | 12:00 | 19:04 | 17:20 | 17:34 | 21:57 | 20:19 | 20:32 | 23:27 | 21:49 | 22:02 |
| 22 | Дш | 1 | 2:18 | 00:45 | 00:58 | 02:57 | 01:15 | 01:28 | 04:37 | 02:45 | 02:58 | 13:18 | 11:32 | 11:45 | 13:30 | 12:00 | 12:00 | 19:04 | 17:21 | 17:34 | 21:57 | 20:19 | 20:32 | 23:27 | 21:49 | 22:02 |
| 23 | Сш | 2 | 2:18 | 00:45 | 00:58 | 02:57 | 01:15 | 01:28 | 04:37 | 02:45 | 02:58 | 13:18 | 11:32 | 11:45 | 13:30 | 12:00 | 12:00 | 19:04 | 17:21 | 17:34 | 21:57 | 20:19 | 20:32 | 23:27 | 21:49 | 22:02 |
| 24 | Чш | 3 | 2:19 | 00:46 | 00:59 | 02:58 | 01:16 | 01:29 | 04:38 | 02:46 | 02:59 | 13:19 | 11:32 | 11:46 | 13:30 | 12:00 | 12:00 | 19:04 | 17:21 | 17:34 | 21:57 | 20:19 | 20:32 | 23:27 | 21:49 | 22:02 |
| 25 | Пж | 4 | 2:19 | 00:46 | 00:59 | 02:58 | 01:16 | 01:29 | 04:38 | 02:46 | 02:59 | 13:19 | 11:33 | 11:46 | 13:30 | 12:00 | 12:00 | 19:04 | 17:21 | 17:34 | 21:57 | 20:19 | 20:32 | 23:27 | 21:49 | 22:02 |
| 26 | Жм | 5 | 2:20 | 00:47 | 01:00 | 02:58 | 01:17 | 01:30 | 04:38 | 02:47 | 03:00 | 13:19 | 11:33 | 11:46 | 13:30 | 12:00 | 12:00 | 19:04 | 17:21 | 17:34 | 21:57 | 20:19 | 20:32 | 23:27 | 21:49 | 22:02 |
| 27 | Шм | 6 | 2:21 | 00:47 | 01:00 | 02:59 | 01:17 | 01:30 | 04:39 | 02:47 | 03:00 | 13:19 | 11:33 | 11:46 | 13:30 | 12:00 | 12:00 | 19:04 | 17:21 | 17:34 | 21:57 | 20:18 | 20:32 | 23:27 | 21:48 | 22:02 |
| 28 | Як | 7 | 2:21 | 00:48 | 01:01 | 03:00 | 01:18 | 01:31 | 04:40 | 02:48 | 03:01 | 13:20 | 11:33 | 11:46 | 13:30 | 12:00 | 12:00 | 19:04 | 17:21 | 17:34 | 21:57 | 20:18 | 20:32 | 23:27 | 21:48 | 22:02 |
| 29 | Дш | 8 | 2:22 | 00:49 | 01:02 | 03:00 | 01:19 | 01:32 | 04:40 | 02:49 | 03:02 | 13:20 | 11:33 | 11:47 | 13:30 | 12:00 | 12:00 | 19:04 | 17:21 | 17:34 | 21:57 | 20:18 | 20:31 | 23:27 | 21:48 | 22:01 |
| 30 | Сш | 9 | 2:23 | 00:49 | 01:02 | 03:01 | 01:19 | 01:32 | 04:41 | 02:49 | 03:02 | 13:12 | 11:34 | 11:47 | 13:30 | 12:00 | 12:00 | 19:04 | 17:21 | 17:34 | 21:56 | 20:17 | 20:31 | 23:26 | 21:47 | 22:01 |

## Колак салсаң, үкенмәссең



* Ураза тоткан кешенең йокысы - гыйбадәт, эндәшмәве – тәсбих, гамәле даими, догасы кабул ителгән, ә гөнаһысы гафу ителгән булыр

* Ураза тотучыны сөендерерп кәефен күтәрәчәк ике нәрсә бар. Берсе – ифтар вакытында уразадан чыкканда сөенү булса, икенчесе – Кыямәт көнендә уразаның савабы белән сөенүдер

* Ураза тотучы кешенең ифтар вакытында кабул ителә торган бер догасы бар

* Җәннәттә әр-Рәййан дигән бер ишек бар. Бу ишектән Кыямәт көнендә бары тик ураза тотучылар гына керәчәк. Аннан ураза тотучылардан башка берәү дә керә алмаячак

* Ураза – ул кешене җәһәннәм утыннан саклый торган калкан

* Чисталык, пакьлек – иманның яртысы, ураза – сабырлыкның яртысы

*Тәмле булсын!*

## Катлы пирог



Камыр өчен: 1 стакан җылы сөткә 1 аш калагы коры чүпрәне салып күпертеп алабыз. Шуңа эретелгән 100 гр ак май, 1 аш калагы шикәр комы, ярты чәй калагыннан әзрәк тоз, 1 йомырка, он салып камыр басабыз. Җылы урында кабартабыз. Эчлек өчен 1 лимон, 2 апельсинны иттарткычтан үткәреп, шикәр комы кушабыз. Камырны өч кисәккә бүләбез. Олырак өлешен җәеп табага куябыз, эчлек җәябез, тагы бәләкәй кисәк камырны җәябез, эчлек салабыз, камыр җәеп өстенә куябыз. Пирог өстенә май, шикәр комы, оннан умач уып сибәбез.


**Нәшире**
**Иршат Гыйльметдин улы ШӘЙХАТТАР**
**Баш мөхәррир**
**Муллагалиева А. Г.**
**Тел.:** (8552) 70-51-09
**Факс:** (8552) 70-51-45

* * *

**Оештыручылары:**
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте, "Ислам нуры" дини эшмәкәрлек Үзәге

Газета мәкаләләрен күчереп басканда аларның "Ислам нуры"ннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән хатларда авторларның стиле саклана.

**Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юллау кирәк.**

**Электрон хатлар өчен:**
islamgazeta@mail.ru

Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятьләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучы сораулары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җавап бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7-0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

"Роспечать" агентлыгы каталогына кертелгән, язылу ел әйләнәсендә Россия Федерациясе буенча алып барыла.

Айга ике мәртәбә чыга.

**Тиражы: 1500**
**Индексы 54149**

* * *


Хөрмәтле укучыбыз!

Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, танышларыгызга, тапшырсагыз иде. "Ислам нуры"ның һәр саны кулдан-кулга күчеп динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.

Шулай ук укучыларыбыз, Коръән аятьләре язылу сәбәпле, газетаны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан сакланыйлар дип ышанабыз.


* * *

Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән "Ислам нуры" басмаханәсендә басылды.

**Нәшир, типография һәм редакция адресы:**
**423802, Яр Чаллы, Үзәк урамы, 72**

**Басарга кул куелды: график буенча 14 май 16 сәг. фактта 14 май 16 сәг.**
**Бәясе ирекле**